Эшне башкару өчен кулланма

Татар теленнән белем һәм күнекмәләрне тикшерү өчен биремнәрне башкаруга 45 минут вакыт бирелә. Тәкъдим ителгән эш 2 өлештән тора.

Беренче өлеш 20 биремне үз эченә ала (А1-А20), сез алар арасыннан дөрес дип уйлаган җавапны сайлап алырга тиеш.

Икенче өлеш В1-В6 биремнәреннән тора. Әлеге биремнәр текстка бәйле рәвештә башкарыла. В1-В6 биремнәренә җавапны сез мөстәкыйль рәвештә формалаштырырга һәм язып куярга тиеш.

Биремнәрне тәкъдим ителгән тәртиптә үтәгез. Аларны үтәү барышында сезнең өчен кыенлык тудырганнары килеп чыксса, әлеге биремне калдырып торып, алдагыларына күчәргә киңәш итәбез. Сез бу биремнәргә, вакытыгыз калган очракта, кабат әйләнеп кайта алачаксыз. Беренче өлештәге биремнәргә якынча 1,5 минут вакыт бирелә. Икенче өлештәге һәр биремгә 2 минут вакытыгызны сарыф итегез.

Дөрес җаваплар, катлаулылыкларыннан чыгып, 1 яки югарырак баллар белән бәяләнәләр. Әлеге балларны бергә кушканнан соң, сезгә гомуми балл чыгарыла, шуңа күрә мөмкин кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җаваплар бирергә һәм күбрәк баллар җыярга тырышыгыз.

Сезгә уңышлар телибез !

3 вариант

1 өлеш (А)

Әлеге өлештәге биремнәрне (А1-А20) үтәгәндә, җавалар бланкында эшләнә торган бирем аста урнашкан, дөрес дип табылган җавап номеры шакмагына «Х» билгесе куегыз.

А1. Бер генә иҗектән торган сүзне табыгыз.

1. сыйныф
2. акбур
3. йорт
4. ботка

А2. Сүзләрнең дөрес язылышы күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

1. коңгыз, моңлы
2. коңгоз, моңлы
3. кыңгыз, мыңлы
4. конгыз, моңло

А3. ъ хәрефе языла торган сүзләр рәтен билгеләгез.

1. аш....яулык, вәг...дә
2. сәнгат..., сәгат...
3. көн...як, нию́аят...
4. табигат..., яш...лек

А4. Татар алфавитында ничә хәреф бар?

1. 39
2. 40
3. 33
4. 35

А5. Кайсы сүздә *ө* хәрефе языла?

1. т…лке
2. м…ктәп
3. дәр…с
4. хәр…ф

А6. Иҗекләргә дөрес бүленгән сүзләр рәтен билгеләгез.

1. кыҥ-гы-р-ау, мо-ҥ-су
2. кү-лмәк, чү-лмәк, куя-н
3. кит-ап-ны, каб-ак,ба-б-ай
4. ба-ла, дә-рес, мәк-тәп

А7. Тулы мәгънә белдерә, күренешләре тәэсирле, сәнгатьле итеп чагылдыра, таркалмый торган сүзтезмәләр бирелгән сүзлекләрне билгеләгез.

1. орфографик сүзлекләр
2. аңлатмалы сүзлекләр
3. тәрҗемә сүзлекләре
4. фразеологик сүзлекләр

А8. Санның билгеләмәсен табыгыз.

1. предметның билгесен белдерә
2. предметның эшен белдерә
3. предметны белдерә
4. предметның санын, исәбен белдерә

А9. Ялгызлык исемнәр булган рәтне күрсәтегез.

1. урман,карга,алмагач
2. Казан,Чаллы,Алабуга
3. авыл,башкала,халыклар
4. Гали,укучы,дус

А10. Кимлек дәрәҗәсендәге сыйфатны күрсәтегез.

1. яшел
2. ямь-яшел
3. яшькелт
4. яшелрәк

А11. II нче затта, юнәлеш килешендә, берлек санда булган алмашлыкны табыгыз.

1. синнән
2. сиңа
3. миңа
4. аны

А12. Предметның билгесен белдерә торган сүз төркеме ничек атала?

1. Фигыль
2. Исем
3. Сыйфат
4. Сан

А13. Кайсы сүздә *ө* хәрефе төшеп калган?

1. сөзг...ч
2. к...зге
3. бөр...
4. төлк...

А14. Кушма сүзләрдән генә торган рәтне күрсәтегез.

1. акча, аккош, савыт
2. ямь-яшел, Айсылу, китап
3. карабодай, өчпочмак, төнбоек
4. дәфтәр, өстәл, Алия

А15. Бу сүзләрдән боерык фигыльләрне аерып күрсәтегез.

Җырласа, утыр, яшәсен,омтылса да,төзе, уйнаган, укы

1. җырласа, яшәсен, омтылса да
2. утыр, төзе, укы
3. уйнаган, җырласа, яшәсен
4. омтылса да,төзе, укы

А16. *Сана, йөгер, укы* **сүзләренең үткән заманда юклык формасын билгеләгез.**

1. санады, йөгерде, язды,
2. санамый, йөгерми, укымый
3. санамады, йөгермәде, укымады
4. санамас, йөгермәс, укымас

А17. Күплек санда, чыгыш килешендә килгән исемне табыгыз.

1. мәктәпнең;
2. укытучыбызның;
3. китаптан;
4. балалардан.

А18. Дөрес язылышны табыгыз.

1. йөз ун биш;
2. йөзунбиш;
3. йөзун биш;
4. йөз унбиш.

А19. Фигыльләрнең төрен билгеләгез.

тырышты,эшләгән,күрдек

1. үткән заман хикәя фигыль
2. киләчәк заман хикәя фигыль
3. хәзерге заман хикәя фигыль
4. шарт фигыль

А20. Күплек сан кушымчаларының дөрес ялгану очрагын билгеләгез.

1. көннәр, төннәр, биремнәр
2. көнләр, төнләр, биремнәр
3. көннәр, төнләр, биремләр
4. көннәр, төннәр, биремләр

2 өлеш (В)

Әлеге өлештәге биремнәрне, тәкъдим ителгән текст ярдәмендә үтәгәндә, җавапларыгызны җавап бланкында В1-В6 саннарының уң ягына беренче шакмактан башлап языгыз. Һәр хәреф яки цифр аерым шакмакка языларга тиеш. Сүзләр яки цифрлар, санап үтелгәндә, аерым шакмакка куелган өтерләр белән аерыла. Җавапларны язганда буш шакмаклар калдырырга ярамый.

(1) Боз кристаллары болытка кайдан килә? (2) Алар су парларыннан ясала. (3) Салкын көнне авыздан чыккан пар да якага, бүреккә бәс булып ята бит әле. (4) Әйе, бик нәфис, нәзакәтле шул кар бөртеге. (5) Температура, дымлылык һәм җил аз гына үзгәрсә, кар бөртеге бөтенләй башка була да куя.

В1. Беренче җөмләдәге нечкә әйтелешле сүзне языгыз.

В2. Беренче җөмләдәге рус теленнән кергән алынма сүзне языгыз.

В3. Сыйфат булган җөмләләрнең санын күрсәтегез.

В4. *Парларыннан* сүзенең килешен күрсәтегез.

В5. Беренче җөмләнең әйтелү максаты буенча төрен языгыз.

В6. *Дымлылык* сүзенең ясалышы ягыннан төрен языгыз.